ГЛАВА
КУРКУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КЫРКҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2021 с.Куркуль № 4

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Кыркүл авыл җирлегенең Кыркүл авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыркүл авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыркүл авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Кыркүл авыл җирлегенең Кыркүл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 17 декабрендә график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Кыркүл авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту;
- урамнарны яктырту;
- су челтәрләрен реконструкцияләү һәм карап тоту;
- авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (парк зонасы);
- күмү урыннарын төзекләндерү;
- дини объектларны төзекләндерү;
- каты көнкүреш калдыклары җыю һәм контейнерлар сатып алу өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру;

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Кыркүл авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыркүл авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Кыркүл авыл җирлеге башлыгы** **Е.А.Косова**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "КУРКУЛЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУРКУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
1605-11124/13

Алексеевск муниципаль районының
Кыркүл авыл җирлеге башлыгының
2021 елның 03 декабрендәге
4 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының**
**Кыркүл авыл җирлегенең Кыркүл авылында**
**үзара салым кертү мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын этаплап уздыру**
**ГРАФИГЫ**

| Тәртип саны | Үткәрү датасы | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| **1** | 17.12.2021 | 11:00 | Татарстан Республикасы, Алексеевск р-ны, Кыркүл ав., Үзәк ур., 42 нче йорт адресы буенча урнашкан Кыркүл АМЙ бинасы | **Яңа ур., Комсомол ур.** |
| **2** | 17.12.2021 | 14:00 | Татарстан Республикасы, Алексеевск р-ны, Кыркүл ав., Үзәк ур., 42 нче йорт адресы буенча урнашкан Кыркүл АМЙ бинасы | **Үзәк ур., Октябрь ур., Мәктәп тык., Тау буе ур., Иван Макаров тык., Совет тык.** |
| **3** | 17.12.2021 | 16:00 | Татарстан Республикасы, Алексеевск р-ны, Кыркүл ав., Үзәк ур., 42 нче йорт адресы буенча урнашкан Кыркүл АМЙ бинасы | **Бакча ур., Колхоз ур.** |